СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ
КАРАР

25 декабрь, 2025 ел Алабуга шәһәре № 31

Алабуга муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2024 елның 11 декабрендәге 399 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Алабуга муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмә нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 83 һәм 86 статьяларына таянып, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлегенең бюджеты турында» 2024 елның 11 декабрендәге 399 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

*1 нче өлештә:*

1 пунктта «3 966 214,1» саннарын «4 923 640,8» саннарына алмаштырырга;

2 пунктта «4 985 444,0» саннарын «5 950 206,8» саннары белән алмаштырырга;

3 пунктта «1 019 229,9» саннарын «1 026 566,0» саннарына алмаштырырга;

*3 нче өлештә:*

1 нче кушымтаның «2025 елга район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаның «2025 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керем күләме» 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

3) 4 статьяда:

3 нче кушымтаның «2025 елга Алабуга муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 1 нче таблицасындагы 1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 нче кушымтаның «2025 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 1 нче таблицасындагы 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

5 нче кушымтаның «2025 елга Алабуга муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (АМР муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлү» 1 нче таблицасындагы 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә;

4 пунктта 2025 елга район бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме «120 351,3» санын «122 368,7» санына алмаштырырга.

5 пунктта:

- бюджет чыгымнары классификациясенең «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» бүлекчәсе буенча:

1) 2025 елга «48 790,8» санын «453,5»санына алмаштырырга.

- бюджет чыгымнары классификациясенең «Мәдәният һәм кинематография» бүлегенең «Мәдәният өлкәсендә башка мәсьәләләр» бүлекчәсе буенча.

4) 8 статьяның «2025 елга бүлеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль учреждениеләрне тоту буенча чыгым йөкләмәләрен үтәүгә җирлекләр бюджетыннан тапшырыла торган башка бюджетара трансфертларны район бюджетында исәпкә алырга» 8 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

5) 16 статьяның «2025 елга өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар күләме» 10 нчы кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү һәм туризм мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

Рәис урынбасары А.В. Косов